Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Рус Кармәте авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2021 елның 29 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып, түбәндәге сораулар буенча 2021 елның 18ноябрендә һәм 25 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәт авылында узган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Рус Кармәте авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Новостройки, Гагарин, Үзәк, Горький, Пушкин, Лашевка урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтү.

2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Рус Кармәте авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су башнясын монтажлау өчен килешү буенча товарлар, материаллар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру

-Рус Кармәте авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләү

“ӘЙЕ” “ ЮК” “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 178 гражданин кертелгән, тавыш бирүдә 112 гражданин катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 81 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 31 кеше тавыш бирде.
- "тыелып калды" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Рус Кармәте авылында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

1."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Рус Кармәте авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Новостройки, Гагарин, Үзәк, Горький, Пушкин, Лашевка урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтү.

2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Рус Кармәте авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су башнясын монтажлау өчен килешү буенча товарлар, материаллар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру

-Рус Кармәте авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләү

3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә,http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәмhttp://pravo.tatarstan.ru/Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ОГРН 1021605359709